**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 5 май № 282

г. Казань

Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын даими нигездә биләгән затлар вәкаләтләрен үтәүгә бәйле тәэмин итеlә торган транспорт хезмәте күрсәтү тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 ел, 4 март, ТРЗ-16 нчы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын даими нигездә биләгән затлар вәкаләтләрен үтәүгә бәйле тәэмин ителә торган транспорт хезмәте күрсәтү тәртибен расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\282.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 5 май, 282 нче карары белән расланды

## Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын даими нигездә биләгән затлар вәкаләтләрен үтәүгә бәйле тәэмин итеслә торган транспорт хезмәте күрсәтү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын даими нигездә биләгән затлар (алга таба – дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар) вәкаләтләрен үтәүгә бәйле тәэмин ителә торган транспорт хезмәте күрсәтү шартларын һәм нигезләрен билгели.

2. Бу Тәртиптә дәүләт вазыйфаларын биләгән затларга транспорт хезмәте күрсәтү дәүләт органнары вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү максатларында аларга эш урыныннан автомобиль транспорты бирүне (алга таба – транспорт хезмәте күрсәтү) аңлата.

3. Дәүләт вазыйфаларын биләгән затларга транспорт хезмәте күрсәтү дәүләт вазыйфаларын биләгән затларга шәхси йөртүче белән эш урыныннан җиңел автомобильне шәхси беркетү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

4. Эш урыныннан автомобиль транспорты бирү рәвешендә транспорт хезмәте күрсәтү «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Аларны биләгәндә эш урыныннан автомобиль транспортын шәхси беркетү юлы белән транспорт хезмәте күрсәтелә торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

6. Дәүләт органының эш тәртибендә билгеләнгән эш вакыты чыкканнан соң, шулай ук ялларда һәм эшләми торган бәйрәм көннәрендә эш урыныннан автомобиль транспорты бирү түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда оператив эш итү максатларында;

дәүләт вазыйфаларын биләгән затларны хезмәт командировкаларына җибәргәндә.

7. Дәүләт вазыйфаларын биләгән затларга транспорт хезмәте күрсәтү өчен файдаланыла торган эш урыныннан бирелгән автомобиль транспортын тотуга норматив чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

---